**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740,село Актаныш, проспект Ленина,дом 58,тел.3-44-40

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт, тел.3-44-40

**КАРАР**

№6 «12» апрель 2021 ел

**«Актаныш авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибен раслау турында» 2007 елның 12 октябрендәге 6.2 номерлы Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив-хокукый актларны «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Актаныш авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибен раслау турында» 2007 елның 12 октябрендәге 6.2 номерлы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 9 пунктындагы 3 пунктчасында «Хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Актаныш җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Актаныш авыл җирлеге Советы рәисе — Э.Н.Фәттахов